**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**25.10.2021** **№ 893**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләргә якын урнашкан чикләрне җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларның әйләнешен дәүләт җайга салуы турында һәм алкоголь продукциясен куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, алкоголь һәм спиртлы продукция әйләнешен җайга салу, Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалар һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча норматив-хокукый актлар кабул итүгә бәйле куркынычларны бәяләү өлкәсендә тиешле чаралар эшләү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына таянып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Расларга:

1.1. Әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия составын;

1.2. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия турында нигезләмәне.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Р. Булгаковка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Ф.Хисамутдинов

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 октябрендәге 893 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Булгаков Мурад Рамил улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе |
| Әхмәтҗанов Нияз Камил улы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Гайфуллина Алина Рафис кызы | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Егорова Марина Ивановна | - Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең Казан территориаль органы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Зиатдинов Рамил Равил улы | - «Биектау үзәк хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |
| Галимова Раиса Камил кызы | - «Биектау үзәк хастаханәсе» ДАССУ табиб-психиатр-наркологы |
| Латыпов Рөстәм Вагыйзь улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча бүлегенең полиция (оператив эш буенча) башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Кошелева Саида Мухамедовна | - Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең баш белгече (килешү буенча) |
| Давликамова Алиса Рәсим кызы | - Биектау районы суд приставлары бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Салкова Эльвира Валентиновна | - Татарстан Республикасы буенча Арча, Биектау районнарында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсенең территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Минһаҗев Раил Равил улы | - Биектау муниципаль районы «Административ-техник инспекция» МКУ җитәкчесе |

2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 25 октябрендәге 893 номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган кайбер оешмаларга һәм объектларга якын урнашкан территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча махсус комиссия (алга таба - Комиссия) алкоголь һәм спиртлы продукция әйләнешен җайга салу, Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалар һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча норматив-хокукый актлар кабул итүгә бәйле куркынычларны бәяләү өлкәсендә тиешле чаралар эшләү максатларында төзелде.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Комиссия турында нигезләмә һәм аның составы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 2. Комиссиянең төп максатлары һәм бурычлары

Комиссиянең төп максатлары һәм бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Татарстан Республикасының сәүдә эшчәнлеге, мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәләрендә җайга салуны гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилдән кергән бәяләмәләрне кабул итү (кире кагу) турында карарлар кабул итү;

2.2. Алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга

һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү мәсьәләләре буенча Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының тәкъдимнәрен түбәндәге максатларда әзерләү:

-алкогольле һәм спиртлы продукциянең законсыз әйләнешенә каршы көрәшкә юнәлдерелгән чараларны эшләү буенча;

- балигъ булмаганнарга алкоголь һәм спиртлы продукция сатуга юл куймау буенча;

- кулланучылар хокукларын яклау механизмнарын камилләштерү;

- алкоголь һәм спиртлы продукцияне сату өлкәсендә административ хокук бозуларны кисәтү.

## 3. Комиссиянең максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру

3.1. Әлеге Нигезләмә белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә карарлар кабул итә.

3.2. Комиссия утырышына билгеләнгән тәртиптә мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләрен чакыра, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуны гамәлгә ашыручы яисә сатуны планлаштыручы сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләре (оешмалары) җитәкчеләрен һәм вәкилләрен тыңлый.

3.3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән оешмаларга һәм объектларга якын территорияләр чикләрен тикшерү өчен билгеләнгән тәртиптә эш төркемнәре төзи.

3.4. Комиссия карарларын әзерләүне тәэмин итә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителми торган оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен билгеләү мәсьәләләре буенча норматив-хокукый актлар проектларына тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша (беренчел билгеләү, элек билгеләнгәннәрен гамәлдән чыгару, оешмаларга һәм объектларга якын территорияләрнең чикләрен арттыру яисә киметү).

3.5. Татарстан Республикасының сәүдә эшчәнлеге, мәдәният, мәгариф һәм сәламәтлек саклау өлкәләрендә җайга салуны гамәлгә ашыручы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасында эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиленең бәяләмәләрен, шулай ук махсус комиссия әгъзалары тарафыннан тәкъдим ителгән норматив хокукый акт проектына искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне карый.

3.6. Норматив хокукый акт проектын хуплау турында яисә аны хуплаудан баш тарту турында бәяләмә чыгара.

## 4. Комиссиянең хокуклары

Үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен Комиссия хокуклы:

4.1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының федераль һәм дәүләт башкарма хакимият органнары белән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән

оешмаларга һәм объектларга якын территорияләр чикләрен билгеләү өлкәсендә оештыру-хокукый рәвешенә һәм милек рәвешенә бәйсез рәвештә предприятиеләр һәм оешмалар вәкилләре белән үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәргә.

4.2. Биектау муниципаль районы администрациясенең, башкарма хакимиятнең федераль һәм дәүләт органнарына район территориясендә җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сату һәм алкоголь продукциясен ваклап сату өлкәсендә закон бозуларның ачыкланган очраклары һәм хуҗалык субъектларының канәгатьләнерлек эшләмәве фактлары буенча чаралар күрү турындагы мәсьәләләрне карарга һәм тәкъдимнәр әзерләргә.

4.3. Законнарны бозулар, шулай ук ук яшәү, сәламәтлек, кулланучылар һәм әйләнә-тирә мохит мөлкәтенә куркыныч янау ачыклаганда, бу хакта җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәткәндә алкоголь продукциясен ваклап сатуга һәм алкоголь продукциясен ваклап сатуга контрольне гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль һәм дәүләт органнарына кичекмәстән хәбәр итәргә.

## 5. Комиссия эшчәнлеген оештыру

5.1. Комиссия Комиссия эшчәнлегенә кагылышлы мәсьәләләр буенча тапшырылган материалларны карый.

5.2. Комиссиягә Рәис җитәкчелек итә.

5.3. Комиссия составына Комиссия рәисе, рәис урынбасары, Комиссия секретаре, Комиссия әгъзалары керә.

5.4. Комиссия рәисе:

- Комиссия утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- Комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;
- Комиссия утырышларында рәислек итә;
- Комиссия әгъзалары арасындагы вазыйфаларны бүлә;
- тәкъдимнәрне көн тәртибенә кертә;
- эш төркемнәрен формалаштыра
- Комиссия кабул иткән карарларның үтәлешенә контрольне оештыра;
- документларны, шул исәптән Комиссиянең утырышлар беркетмәләрен имзалый;
- Комиссия утырышларында хәлиткеч тавыш хокукына ия.

5.5. Комиссия рәисе урынбасары:

- Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныша;
- Комиссия компетенциясендәге мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертә;
- Комиссия һәм аның рәисе йөкләмәләрен үти;
- Комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаган очракта башкара.

5.6. Комиссия әгъзалары:

- Комиссия утырышы көн тәртибенә тәкъдимнәр кертәләр;
- Комиссия карый торган мәсьәләләр буенча материаллар белән танышалар;
- Комиссия һәм аның рәисе күрсәтмәләрен үтиләр;
- Комиссия утырышына сораулар әзерләүдә катнашалар һәм аның карарларын үтәү буенча кирәкле чараларны гамәлгә ашыралар;
- үз компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча Комиссия утырышларында доклад ясыйлар;

5.7. Комиссия утырышларында катнашу өчен карала торган аерым мәсьәләләр буенча комиссия әгъзасы булып тормаган контрольлек итүче, хокук саклау, күзәтчелек органнары, иҗтимагый һәм башка хуҗалык итүче субъектлар мәнфәгатьләрен тәкъдим итүче оешмаларның вәкилләре чакырылырга мөмкин.

5.8. Комиссия секретаре:

- Комиссия утырышларын әзерләүне, кирәкле документларны рәсмиләштерүне һәм таратуны да кертеп, Комиссия каравына чыгарылган барлык мәсьәләләр буенча Комиссия әгъзаларына мәгълүмат бирүне, шул исәптән Комиссия эшендә катнашучы затларга утырышларны уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә һәм Комиссия әгъзаларын кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

- Комиссия утырышларын үткәрү барышында, Комиссия секретаре Комиссия утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә;

- Комиссия эшчәнлегенә бәйле документларны саклауны тәэмин итә;

- Комиссия рәисе һәм Комиссия рәисе урынбасары кушуы буенча Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган башка кирәкле оештыру чараларын үти;

- Комиссия утырышында катнашучы хуҗалык субъектлары вәкилләре турында мәгълүматны беркетмәгә кертә.

5.9. Комиссия утырышлары Биектау муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмаларга һәм объектларга якын территорияләр чикләрен билгеләү буенча карарларны раслау яисә үзгәрешләр кертү кирәк булган саен үткәрелә, Комиссия утырышларын үткәрү вакытын һәм урынын Комиссия рәисе билгели.

5.10. Утырышта Комиссия әгъзалары, оешма вәкилләре һәм чакырылган башка затлар тыңлана.

5.11. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзалары санының өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

5.12. Карар ачык тавыш бирү юлы белән махсус комиссия әгъзаларының утырышта катнашучы гомуми санының кимендә өчтән икесенең күпчелеге белән кабул ителә.

5.13. Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы Комиссия секретаре имзалый.

5.14. Комиссия карары нигезендә хуҗалык итүче субъектка 10 эш көне эчендә Комиссия утырышы беркетмәсеннән өземтә тапшырыла.

5.15. Комиссия тәкъдим ителгән материалларны тикшерүне билгеле бер срокка, әмма өч айдан да артык булмаган вакытка дәлилләнгән карар белән кичектерергә мөмкин.

5.16. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник тәэмин итү, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

5.17. Кабул ителгән карар белән риза булмаган Комиссия әгъзасы үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы, ул Комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушып бирелергә тиеш.